ЛЕНИНОГОРСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
ЛЕНИНОГОРСК
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

6.08.2021 г.Лениногорск № 50

Татарстан Республикасы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Лениногорск шәһәр Советының 2013 елның 27 декабрендәге 121 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 29 декабрендәге 468-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәр Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Лениногорск шәһәр Советының 2013 елның 27 декабрендәге 121 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

**30 статьяның 6 өлешендә** «утыз көн» сүзләрен «егерме биш көн» сүзләренә алыштырырга;

**16 статьяның 1 өлешендә** «капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү» сүзләреннән соң «мондый рөхсәт бирү турында гариза

кергән көннән алып унбиш эш көне эчендә әзерләнә.» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны рәсми публикаторда урнаштырырга, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш комиссиясенә йөкләргә.

Лениногорск шәһәре
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Лениногорск шәһәре мэры Р.Г.Хөсәенов